КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 2 сентябрь г.Казань № 750

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елда Казан шәһәрендә «Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә һөнәри осталык буенча дөнья чемпионатын әзерләүгә бәйле чараларны финанслау турында» 2016 ел, 27 октябрь, 790 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республики Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елда Казан шәһәрендә «Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә һөнәри осталык буенча дөнья чемпионатын әзерләүгә бәйле чараларны финанслау турында» 2016 ел, 27 октябрь, 790 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 29 декабрь, 1263 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2019 елда Казан шәһәрендә «Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә һөнәри осталык буенча дөнья чемпионатын әзерләүгә бәйле чараларга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчалардан файдалану кагыйдәләрендә:

1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Башка бюджетара трансфертлар «Мәгариф» илкүләм проектының «Яшь профессионаллар (һөнәри белем бирүнең көндәшлеккә сәләтен арттыру)» федераль проектының «Казан шәһәрендә 2019 елда «Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә һөнәри осталык буенча дөнья чемпионаты үткәрелде» нәтиҗәсенә ирешү максатларында бирелә.»;

7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Министрлык квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 25еннән дә соңга калмыйча, иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең «Электрон бюджет» дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында финанслар белән тәэмин итү максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турындагы хисапны, башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәләре мәгънәсенә ирешү турындагы хисапны, 2019 елда Казан шәһәрендә «Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә һөнәри осталык буенча дөнья чемпионатын әзерләүне һәм үткәрүне тәэмин итә торган эшләр башкару һәм хезмәт күрсәтүләр турындагы хисапны Россия Федерациясенең Мәгариф министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелгән килешүдә каралган форма буенча һәм тәртиптә Россия Федерациясенең Мәгариф министрлыгына һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына кертә.»;

әлеге карар белән расланган 2019 елда Казан шәһәрендә «Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә һөнәри осталык буенча дөнья чемпионатын әзерләүгә бәйле чаралар өчен 2019 елда Казан шәһәрендә «Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә һөнәри осталык буенча дөнья чемпионатын әзерләү һәм үткәрү буенча башкарма оешмага субсидияләр бирү тәртибендә:

10 нчы пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Килешүдә субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, субсидияне күчерү тәртибе һәм вакытлары, субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе, финанслар белән тәэмин итү максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында хисап, башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәләре мәгънәсенә ирешү турында хисап, 2019 елда Казан шәһәрендә «Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә һөнәри осталык буенча дөнья чемпионатын әзерләүне һәм үткәрүне тәэмин итә торган эшләр башкару һәм хезмәт күрсәтүләр турында хисап бирү вакытлары һәм формасы, аны биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган һәм (яки) субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсенә ирешелмәгән очракларда субсидияне кире кайтару тәртибе, хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешләрен агымдагы финанс елында кире кайтару очраклары, субсидия акчасы исәбеннән чит ил валютасы сатып алуны тыю югары технологияле чит ил җиһазы, чимал һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш), Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының оешма тарафыннан субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешенә тикшерүләр үткәрүенә оешма ризалыгы күздә тотыла.»;

13 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Оешма субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсенә ирешү турындагы хисапны, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турындагы хисапны һәм 2019 елда Казан шәһәрендә «Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә һөнәри осталык буенча дөнья чемпионатын әзерләүне һәм үткәрүне тәэмин итә торган эшләр башкару һәм хезмәт күрсәтүләр турындагы хисапны Министрлыкка килешү белән күздә тотылган тәртип, вакытлар һәм форма нигезендә кертә.»;

14 нче пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсенә ирешү турындагы хисап, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турындагы хисап һәм 2019 елда Казан шәһәрендә «Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә һөнәри осталык буенча дөнья чемпионатын әзерләүне һәм үткәрүне тәэмин итә торган эшләр башкару һәм хезмәт күрсәтүләр турындагы хисап тапшылырмаган, хисап тапшыру вакытлары бозылган очракларда, тулы күләмдә;»;

бишенче абзац үз көчен югалткан дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин